| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.12.2018 Буа шәһәре № 415/ИК-п

Буа муниципаль районында төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча эшнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Административ хокук бозулар турындагы кодексы (алга таба 2010 елның 30 июлендәге 61-ТРЗ номерлы үзгәрешләр белән), Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Буа муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә контрольне көчәйтү өчен ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРДЕ:

1. Буа муниципаль районында төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча эшнең административ регламентын (алга таба – Регламент) китерелгән кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе Р.Р. Кәмәртдинов

Буа муниципаль районы
Башкара комитетының
2018 елның 24 декабрендәге
415/ИК-п номерлы карарына
кушымта

# Буа муниципаль районында төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча эшнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Буа муниципаль районында төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча эшнең административ регламенты юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актларны үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү фактларын ачыклау максатында эшләнгән һәм муниципаль контрольне башкаргандагы гамәлләрнең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Муниципаль контроль һәм башка контроль чараларын оештыру һәм башкару функцияләре түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла: Россия Федерациясе Конституциясе; «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы; «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы; Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы; Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турындагы кодексы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы; Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы; Буа шәһәр Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 3-27 номерлы карары белән расланган ТР Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре; Буа районы Башкарма комитетының «Буа муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын раслау турында» 2014 елның 25 гыйнварындагы 12-п номерлы карары; гамәлдәге Регламент.

1.3. Тикшерү нәтиҗәләре булып тикшерү актын тутыру, тикшерелүче субъектның эшчәнлегендә тәртип бозулар ачыкланганда чаралар күрү тора. Административ регламент көче реклама таратучыларның Буа муниципаль районы муниципаль милкендә булган милекне файдаланып реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә килешү шартларын үтәвенә контрольне башкаруга кагылмый.

1.4. Территорияне төзекләндерү өлкәсендә контроль предметына түбәндәге тикшерү керә:

а) төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, Буа муниципаль районы территориясендә чисталыкны һәм тәртипне тәэмин итү;

б) төзелешләр, биналар, корылмаларны урнаштыру, төзү, ремонтлау, төзекләндерү һәм яңадан планлаштыру процессында Буа муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитеты) рөхсәте булуы һәм башкарган эшләрнең проект документациясенә тәңгәл килүе;

в) тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатациягә рөхсәт булуы;

г) территорияне яшелләндерү буенча чаралар күрүгә, инженерлык коммуникацияләрен салу, яңадан урнаштыру һәм ремонтлау, юллар төзү һәм ремонтлау белән бәйле җир эшләрен үткәрүгә Башкарма комитет рөхсәте булуы;

д) кече ваклап сату сәүдә челтәре аша сәүдә итүгә рөхсәт булуы.

1.5. Тикшерүләр Башкарма комитетының структур бүлекчәсе вәкаләтле затлары тарафыннан тикшерүләр планы нигезендә яисә физик һәм юридик затлар, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләре буенча үткәрелә.

1.6. Буа муниципаль районы административ комиссиясе рәисе гамәлдәге Регламентның 1.2 пункты нигезендә тышкы төзекләндерү өлкәсендә юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан муниципаль хокукый актларның үтәлешен тикшерүне оештыра һәм аның нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарында юридик, вазыйфаи һәм физик затларга карата каралган чараларны күрә.

1.7. Әлеге Регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән затларга карата контроль чараларын оештыру һәм үткәрү законлылык һәм аларның намуслылык презумпциясе принциплары нигезендә башкарыла.

1.8. Тышкы төзекләндерү өлкәсендә юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан муниципаль хокукый актларның үтәлешен тикшерү функцияләрен башкаруның фактик нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

а) тикшерү нәтиҗәләре турында акт төзү һәм тапшыру;

б) тышкы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозуны бетерү турында күрсәтмә тапшыру;

в) тышкы төзекләндерү өлкәсендә административ хокук бозу кылынуы турында беркетмә төзү;

1.9. Тышкы төзекләндерү өлкәсендә контроль функцияләрен үтәү бушлай нигездә башкарыла.

## 2. Тышкы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне башкарганда административ процедуралар

<u>Контроль функцияләрен үтәү тәртипләренә таләпләр</u>

2.1. Муниципаль контроль органы әлеге Регламентның 1.2 пункты нигезендә юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тышкы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актларның үтәлешенә муниципаль контрольне башкара. Контроль буенча чаралар түбәндәге эзлеклелектә башкарыла:

1) тикшерүләрне планлаштыру;

2) тикшерүләр үткәрүгә әзерлек;

3) тикшерүләр үткәрү һәм аларның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

4) тикшерү барышында ачыкланган тәртип бозу фактларына карата чалар күрү;

5) тышкы төзекләндерү өлкәсендә закон бозуларны бетерү артыннан контроль.

2.2. Тышкы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне башкару тәртибе.

Эш вакыты: Дүшәмбе-җомга 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Шимбә, якшәмбе – ял. Төшке аш – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

Гражданнарны кабул итү: Дүшәмбе-җомга 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Административ комиссия кабинеты Буа шәһәре, Жорес урамы, 110нчы “А” йорт адресы буенча урнашкан. Телефон: 3-18-93. Интернеттагы адрес: buinsk.tatarstan.ru.

<u>Планлы тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибе</u>

2.3. Планлы тикшерү предметы булып юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерү тора.

2.4. Планлы тикшерүгә нигез булып муниципаль контроль органын еллык тикшерү планы тора.

2.5. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан ешрак үткәрелми.

2.6. Еллык тикшерү планында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) эшчәнлекләре планлы тикшерелергә тиеш юридик затларның атамалары (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре), шәхси эшмәкәрләрнең фамилияләре, исемнәре, атасы исемнәре, юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан урыны яки шәхси эшмәкәрләрнең яшәү урыны һәм алар үз эшчәнлеген фактик башкарган урыны;

2) һәр планлы тикшерүне үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) тикшерү үткәрүнең датасы һәм сроклары;

4) планлы тикшерү башкарган муниципаль контроль органы атамасы.

2.7. планлы тикшерүләр үткәрүнең расланган еллык планы кызыксынган затлар игътибарына аны муниципаль контроль органының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән яисә башка үтемле ысул белән җиткерелә.

2.8. Планлы тикшерүләр үткәрү елы алдындагы елның 1 сентябренә кадәр срокка муниципаль контроль органы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы нигезләмәләрен исәпкә алып, Буа районы прокуратурасына планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектын юнәлдерә.

Муниципаль контроль органы прокуратура органнары тәкъдимнәрен карый һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча планлы тикшерүләр үткәрү елы алдындагы елның 1 ноябренә кадәр срокка планлы тикшерүләр үткәрүнең расланган еллык планнарын прокуратура органнарына җибәрә.

2.9. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына планлы тикшерүләрне кертү өчен нигезләр «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы белән билгеләнгән.

2.10. Юридик затка, шәхси эшмәкәрләргә планлы тикшерү үткәрү турында муниципаль контроль органы тарафыннан тикшерү үткәрүне башлаганчы өч көннән дә соңармыйча муниципаль контроль җитәкчесенең планлы тикшерү үткәрү турындагы карары күчермәсе тапшыру турындагы белдерү белән заказлы почта җибәрүе яки курьер аша хәбәр ителә.

2.11. Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы тикшерү үткәрүнең гомуми срогы елына кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микро предприятие өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

2.12. урынга чыгып планлы тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органы вазыйфаи затының дәллиле тәкъдиме нигезендә махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү таләп ителү белән бәйле аерым очракларда, урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү срогы муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин кече предприятиеләргә карата 20 эш көненнән дә артмаска, микро предприятиеләргә карата 15 сәгатьтән дә артмаска тиеш.

<u>Планнан тыш тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибе</u>

2.13. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) юридик зат, вазыйфаи һәм физик зат тарафыннан зарури таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын юкка чыгару турында элек бирелгән күрсәтмәне үтәү вакыты узу;

2) муниципаль контроль органына гражданнардан, шул исәптән юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәгеләр фактлар хакында мәгълүматлар керү:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, дәүләт иминлегенә зыян салыну, шулай ук табигый һәм

техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычларының барлыкка килүе турында;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, дәүләт иминлегенә зыян салыну, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүе хакында;

в) кулланучыларның хокуклары бозылу турында (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта);

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә һәм прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча прокурорның законнар үтәлешен күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерүне үткәрү турындагы таләбе нигезендә муниципаль контроль органы җитәкчесенең боерыгы.

2.14. Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать итүче затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук 2.13 пунктның “а” һәм “б” пунктчаларында күрсәтелгән фактлар турындагы белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмыйлар.

2.15. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында муниципаль контроль органы юридик затка, шәхси эшмәкәргә аны үткәрә башлаганчы егерме дүрт сәгатьтән соңга калмыйча телефонограмма, курьер аша хәбәр итә.

2.16. Планнан тыш тикшерүнең предметры булып юридик, вазыйфаи һәм физик зат тарафыннан зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәве, муниципаль контроль органы күрсәтмәләрен үтәве, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелүгә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә зыян салынуга юл куймау, дәүләт иминлеген тәэмин итү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүен кисәтү, андый зыян китерелүнең нәтиҗәләрен юк итү буенча чаралар күрү.

2.17. Һәр тикшерү үткәрүнең срогы 20 эш көненнән арта алмый.

<u>Тикшерү үткәрү тәртибе</u>

2.18. Муниципаль контроль үткәрү буенча функцияне башкару үзенә түбәндәге административ процедураларны ала:

контроль буенча чаралар үткәрү турында карар чыгару;

контроль буенча чаралар әзерләү һәм тикшерелүче оешмага белдерү җибәрү;

контроль буенча чаралар үткәрү; күрсәтмәләр төзү һәм тапшыру.

2.19. Тикшерү муниципаль контоль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасар) карары нигезендә үткәрелә.

2.20. Муниципаль контоль органы җитәкчесе карарында күрсәтелә:

1) муниципаль контоль органы атамасы;

2) тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрүгә җәлеп ителүче экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, атасы исемнәре;

3) эшчәнлекләре планлы тикшерелергә тиеш юридик затның атамасы яки шәхси эшмәкәрләрнең фамилиясе, исеме, атасы исеме, юридик затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан урыны яки шәхси эшмәкәрләрнең яшәү урыны һәм алар үз эшчәнлеген фактик башкарган урыны;

4) тикшерүнең максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү срогы;

5) тикшерү үткәрүнең, шул исәптән зарури таләпләр һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне тикшерүнең хокукый нигезләре;

6) үткәрү сроклары һәм контроль буенча тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешергә кирәкле чаралар исемлеге;

7) тышкы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль башкару буенча гамәлдәге регламентның атамасы;

8) тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешергә кирәкле юридик зат, шәхси эшмәкәр тәкъдим итәргә тиешле документлар исемлеге;

9) тикшерү үткәрүне башлау һәм төгәлләү даталары.

2.21. Карар тикшерү үткәргән муниципаль контроль органының вазыйфаи заты имзасы белән берьюлы хезмәт таныклыкларын да күрсәтеп, юридик затның җитәкчесенә,

вазыйфаи затына, вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка тапшырыла.

2.22. Тикшерүче юридик затның җитәкчесе, вазыйфаи заты, вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, физик зат үтенече белән тикшерелергә тиешле затларны контроль буенча чаралар үткәрүнең административ регламенты белән, шулай ук юридик зат, шәхси эшмәкәр үз эшчәнлеген башкарганда файдалана торган объектларда аларны үткәрү тәртибе белән таныштырырга тиеш.

2.23. Муниципаль контроль башкаручы вазыйфаи зат үткәрелгән тикшерү турында язуны тикшерүләрне исәпкә алу журналына РФ Икътисади үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында»гы Федераль законның нигезләмәләрен гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган формада кертә.

2.24. Тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль контроль органының тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары тарафыннан билгеләнгән формада ике экземплярда акт төзелә.

Актта күрсәтелә:

1) тикшерү актын төзүнең датасы, вакыты һәм урыны;

2) муниципаль контроль органының атамасы;

3) муниципаль контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карарының датасы һәм номеры;

4) тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, атасы исемнәре һәм вазифалары;

5) тикшерү үткәргәндә катнашкан тикшерелүче юридик затның атамасы һәм шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасы исеме, шулай ук юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәр вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасы исеме, вазифасы, физик затның фамилиясе, исеме, атасы исеме.

6) тикшерү үткәрүнең датасы, вакыты, озынлыгы һәм урыны;

7) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыклану турындагы, аларның характеры һәм күрсәтелгән бозуларга юл куйган затлар турында мәгълүматлар;

8) тикшерү үткәргәндә катнашкан юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, физик затның тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы, аларның имзалары яки имза куюдан баш тартулары турында мәгълүматлар, шулай ук үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына язулар кертү турында яисә юридик затта, шәхси эшмәкәрдә әлеге журнал булмау сәбәпле андый язуны кертә алмау турында мәгълүматлар;

9) тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның имзалары.

2.25. Тикшерү үткәргәндә мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта, тикшерү үткәргән муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында каралган үзләренең вәкаләтләре чикләрендә мәҗбүр:

1) юридик затка, шәхси эшмәкәргә ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең срокларын күрсәтеп күрсәтмә бирергә;

2) ачыкланган бозуларны бетерүне контрольгә алу, аларның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүен, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, дәүләт иминлегенә зыян салынуын, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычлары барлыкка килүен кисәтү һәм моңа юл куймау буенча чаралар, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә.

2.26. Бозу факты булуын дәлилләүләр законда тыелмаган теләсә нинди ысул белән теркәлә ала (фото, видеога төшерү, бозу булганын расларга мөмкин затларның аңлатмалары һ.б.).

## 3. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Контроль башкару буенча йөкләнләнгән бурычларны үтәү өчен вәкаләтле органның вазыйфаи затлары хокуклы:

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге гамәлдәге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, хезмәт таныклыгын һәм тикшерү үткәрү турында карарны яисә әлеге карарның мөһер белән раслатылган күчермәсен күрсәтеп, объектларга керергә;

тикшерелүче заттан тикшерү үткәрү белән бәйле рәвештә, башкарылган эшләрнең нәтиҗәләрен, документацияләрне күрсәтүне таләп итәргә;

үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча актлар төзергә, аларның нигезендә ачыкланган тәртип бозуларны бетерү турында таләпләр куела;

тикшерелүче затның гамәлләрендә административ хокук бозулар күренеше ачыкланган очракта үткәрелгән тикшерү турында актны, аңа теркәлгән хат белән бергә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле тиешле органга җибәрергә;

тикшерелүче заттан территорияләрне төзекләндерү өлкәсендә гамәлдәге законнарның нормаларын һәм муниципаль хокукый актларның үтәлешен таләп итәргә;

ачыкланган тәртип бозуларны бетерү һәм гаепле затларны законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, күзәтчелек органнарына яисә судка мөрәҗәгать итәргә;

гамәлдәге законнар нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, Башкарма комитет структурасына керүче органнардан, барлык милек формаларындагы оешмалардан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне һәм башка документларны сорарга һәм алырга;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3.2. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары контроль башкару белән бәйле чаралар үткәргәндә хокуклы түгел:

мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең, әгәр андый таләпләр муниципаль контроль органы вәкаләтләренә карамаса, үтәлешен тикшерергә;

тикшерү предметына кагылмаган документларны, мәгълүматларны тәкъдим итүне таләп итәргә;

юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органы ведомствосы яки җирле үзидарә органы оешмалары карамагында булган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документлар һәм (яки) мәгълүматларны, шул исәптән рөхсәт документларын тәкъдим итүне таләп итәргә;

тикшерү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән сакланган башка сер булган мәгълүматларны таратырга;

тикшерү үткәрүгә билгеләнгән срокларны арттырырга;

юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә алар исәбенә контроль буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирүне башкарырга.

3.3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча чаралар үткәргәндә муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары бурычлы:

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын, муниципаль хокукый актларны, тикшерелә торган затның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

муниципаль контроль чараларын гамәлгә ашырганда юридик затларның, шәхси эшкуарларның һәм гражданнарның хокукларын яклау буенча закон таләпләрен үтәргә;

җирлек территориясен төзекләндерү өлкәсендәге тәртип бозуларны булдырмау, ачыклау, юл куймау һәм бетерү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә кирәкле чаралар күрергә;

район территориясенең тышкы төзекләндерү өлкәсендә хокук бозулар турындагы гаризаларны һәм хәбәрләрне оператив рәвештә карарга, аларны бетерү буенча үз вакытында чаралар күрергә.

3.4. Муниципаль контроль буенча чаралар үткәргәндә тикшерелә торган зат хокуклы:

тикшерү үткәрү барышында катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

муниципаль контроль органнарыннан, аларның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагылышлы, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы буенча тәкъдим ителергә тиешле мәгълүматны алырга;

тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу, алар белән, шулай ук дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән ризалашу яки ризалашмау турында күрсәтергә;

тикшерү үткәргәндә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокуклары бозылуга китергән дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә.

3.5. Тикшерелүче зат муниципаль контроль буенча чаралар үткәргәндә бурычлы:

муниципаль контроль буенча чаралар уздырганда үзенең катнашуын яки үз вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә;

күрсәтелгән чараларны үтәгәндә муниципаль контроль чараларын оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм итәргә.

## 4. Муниципаль контроль башкаруны контрольдә тоту формалары һәм тәртипләре

4.1. Вазыйфаи затларның муниципаль контроль административ процедуралары белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәвенә, аларның карарлар кабул итүенә агымдагы контроль даими нигездә муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.2. Муниципаль контроль буенча тикшерүләр үткәрүнең тулылыгына һәм сыйфатына гомуми контроль үз эченә юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерү буенча тикшерүләр үткәрүне, аларның муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдергән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү һәм карарлар кабул итүне, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының муниципаль контрольне башкарганда хезмәт бурычларын тиешенчә башкармау очракларын исәпләп баруны ала.

4.2.1. Гомуми контроль планлы һәм плансыз тикшерүләр юлы белән башкарыла. Тикшергәндә йә муниципаль контроль башкару белән бәйле барлык сораулар (комплекслы тикшерү), яисә аерым аспектлар (тематик тикшерүләр) карала.

4.2.2. Планнан тыш тикшерү тикшерелүче затның яки аның вәкаләтле вәкиленең конкрет мөрәҗәгате (шикаяте) буенча үткәрелә.

4.2.3. Тикшерү нәтиҗәләре акт рәвешендә төзелә, анда ачыкланган тәртип бозулар һәм җитешсезлекләр теркәлә, шулай ук аларны бетерү буенча тәкъдимнәр күрсәтелә.

4.2.4. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары гамәлдәге законнар нигезендә һәр административ процедураны башкару срокларын һәм тәртипләрен үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

4.2.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контроль үткәрү мөстәкыйль контроль формасы булып тора һәм мөрәҗәгать җибәрү юлы белән, шулай ук тикшерү үткәрү барышында башкарылган (кабул ителгән) карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять бирү юлы белән башкарыла.

## 5. Муниципаль контроль үтәүче органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, гражданнар, аның вәкаләтле вәкиле администрация вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданнарның хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына), Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

5.2. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять юридик зат, шәхси эшмәкәр, гражданин тарафыннан кәгазьдә язмача формада яисә электрон формада муниципаль контроль органы җитәкчесенә бирелә.

5.2.1. Шикаять эчтәлегендә булырга тиеш:

язмача мөрәҗәгать юнәлдерелгән җирле үзидарә органының атамасы, яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасы исеме, яисә тиешле затның вазифасы;

шикаять бирүче турында мәгълүматлар, җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

шикаять белдерелгән гамәлләр (гамәл кылмау) һәм карарларның нигезе;

шикаять бирүченең шәхси имзасы (мөһер – юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен) һәм имзалау датасы.

5.2.2. Тикшерелүче зат үзенең шикаятендә анда язылган хәлләрне исбатлаучы документларның күчермәсен беркетергә хокуклы. Бу очракта шикаятьтә аңа кушымта итеп бирелгән документларның исемлеге дә языла (почта аша җибәрелгәндә салынган документларның исемлеге языла).

5.3. Шикаять аны теркәгән көннән утыз көн эчендә карала.

5.4. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүнең нәтиҗәсе түбәндәгеләр була:

шикаять бирүченең таләпләрен тулысынча яисә өлешчә канәгатьләндерү;

шикаять бирүченең таләпләрен тулы күләмдә яисә өлешчә канәгатьләндерүне кире кагу.

Шикаять каралган нәтиҗәләрне үз эченә алган язмача җавап шикаять бирүчегә тапшыру турында белдерү белән почта җибәрүе аша яисә аның таләбе буенча кулга тапшырыла.

5.5. Вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауга) шикаятьләр түбәндәге очракларда каралмый:

әгәр шикаятьтә шикаять бирүченең фамилиясе, җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса шикаятькә җавап бирелми. Әгәр әлеге шикаятьтә законга каршы гамәл әзерләнүе, кылынуы яки кылынганы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүмат булса, шикаять тиешле дәүләт органына аның компетенциясе нигезендә җибәрелергә тиеш;

әгәр шикаятьтә әдәпсез яки мыскыл итүче сүзләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм милкенә янаулар булса, анда куелган мәсьәләләрнең нигезе буенча җавапсыз калдырыла, шикаять бирүчегә бу хакта язмача хәбәр ителә;

әгәр шикаять текстын укып булмаса, шикаятькә җавап бирелми, әгәр шикаять бирүченең фамилиясе һәм почта адресы укырлык булса, аңа бу хакта язмача хәбәр ителә.

5.6. Тикшерелүче зат муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләре әлеге админстратив регламентны үтәү барышында кабул иткән карарларына һәм гамәлләренә (гамәл күрмәвенә), Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, судка шикаять бирергә хокуклы.